ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1984 от 22.12.2025

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районында гражданнар оборонасы штабын төзү турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 1535 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гражданнар оборонасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районында гражданнар оборонасы штабын төзү турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 1535 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 бүлегендәге 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар оборонасы өлкәсендәге таләпләр - гражданнар оборонасы идарәсенең техник системаларын, яшеренү урыннарын һәм гражданнар оборонасының башка объектларын булдыруның, эксплуатацияләүнең, халыкка хәбәр итү системаларын куллануга, башка махсус техниканы һәм граждан оборонасы милкен файдалануга һәм карап тотуга, халыкны индивидуаль яклау чаралары белән тәэмин итүгә, халыкны эвакуацияләүне оештыруга, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклауга әзерлекнең махсус шартлары (кагыйдәләре, тәртибе).».

1.2. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 23 абзацында «хәрби конфликтлар булганда яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында халык өчен» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. Нигезләмәнең 2 пунктындагы 24 абзацында «хәрби конфликтлар булганда яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «хәвеф-хәтәрләр килеп чыгу нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 74 абзацында «хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында барлыкка килгән» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 20 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.А. Томилин